**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 март № 195

г. Казань

Төбәк операторы эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 186 статьясындагы 1 өлеше, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк операторы эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\195.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 март, 195 нче
карары белән расланды

## Төбәк операторы эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм төбәк операторы эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне, шулай ук күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фондын формалаштыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру процедурасын билгели.

2. Бу Тәртиптә файдаланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар:

төбәк операторы - «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы;

тикшерү – Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – Инспекция) төбәк операторына карата күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән ул башкара торган эшчәнлекнең яки гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү өчен үткәрә торган тикшерүдә тоту чаралары җыелмасы;

тикшерү акты – Инспекциянең вазыйфаи затлары тикшерү нәтиҗәләре буенча төзи торган документ.

3. Төбәк операторының эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерүдә тотуны Инспекция тикшерүләр үткәрү, төбәк операторыннан законнарда каралган мәгълүматларны алу ярдәмендә (бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча төбәк операторы исәбенә (исәпләренә) урыннар милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр кертү турындагы мәгълүматны кертеп), шул исәптән Инспекциянең https://bars-monjf.tatar.ru/monjf/ адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган дәүләт программасын төзү һәм үтәлешен мониторинглау һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглау интеграцияләнгән мәгълүмат-анализ системасыннан файдаланып, гамәлгә ашырыла.

4. Тикшерү теләсә нинди ешлык белән һәм планлы тикшерүләрнең еллык планын төземичә үткәрелә. Тикшерүләр үткәрү вакыты чикләнми. Төбәк операторына планнан тыш тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә

һәм мондый тикшерүләр үткәрү турында төбәк операторына алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

5. Тикшерү Инспекция башлыгының тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү бары тик тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

6. Документар тикшерү үткәргәндә Инспекция төбәк операторына документар тикшерү үткәрү өчен кирәк булган документларны күрсәтелгән вакытта кертү турында үтенеч җибәрә. Төбәк операторы үтенечтә күрсәтелгән документларны Инспекциягә үтенечтә күрсәтелгән вакытта кертә. Документлар төбәк операторы җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән таныкланган күчермәләр рәвешендә кертелә.

7. Күчмә тикшерүләр документар тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне эшләп булмаганда үткәрелә:

төбәк операторының Инспекция карамагында булган документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ианып булмаганда;

тикшерүдә тоту буенча күчмә чара үткәрмичә төбәк операторының эшчәнлеге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне бәяләп булмаганда.

8. Күчмә тикшерү үткәргәндә төбәк операторы тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга кирәкле оештыру һәм техник ярдәм күрсәтергә, шул исәптән аларны кирәкле урыннар, оештыру техникасы, канцелярия кирәк-яраклары һәм тикшерү үткәрү өчен кирәкле башка чаралар белән тәэмин итәргә тиеш.

9. «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль законны бозуларга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез каршылык тудыручы, тикшерүләр үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) ачыкланган закон таләпләрен бозуларны бетерү турында Инспекциянең вазыйфаи затлары биргән күрсәтмәләрне билгеләнгән вакытта үтәмәүче төбәк операторы, төбәк операторы җитәкчесе, башка вазыйфаи затлар һәм төбәк операторының вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

10. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекциянең тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2009 ел, 30 апрель, 141 нче боерыгы белән расланган форма буенча тикшерү акты төзи.

11. Тикшерү акты аны үткәреп бетергәннән соң турыдан-туры ике нөсхәдә төзелә, аның бер нөсхәсе кушымталарының күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки төбәк операторының вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу турында яки аның белән танышудан баш тарту хакында кул куйдыртып тапшырыла. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки төбәк операторының вәкаләтле вәкиле булмаса, шулай ук тикшерүче зат тикшерү акты белән танышуы турында йә аның белән танышудан баш тартуы хакында кул куеп раслаудан баш тартса, акт аның илтеп тапшырылуы турындагы хәбәрнамә белән Инспекциядә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлүче заказлы хат белән почта аша җибәрелә.

12. Тикшерү үткәргәндә төбәк операторының закон таләпләрен бозу очраклары ачыкланган очракта, Инспекциянең тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

билгеләнгән таләпләрне бозуларны туктату турында, ачыкланган тәртип бозуларны бетерү хакында, билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итү чараларын үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

ачыкланган тәртип бозуларны бетерүне, аларны кисәтүне тикшерүдә тоту чараларын, шулай ук тәртип бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрергә.

13. Төбәк операторы тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр йә бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, ул тикшерү актын алган көннән унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү акты һәм (яки) бирелгән күрсәтмә белән тулаем яки аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәве турында язма рәвештә белдерергә хокуклы. Бу вакытта төбәк операторы мондый килешмәүләрнең нигезле булуын раслый торган документлар яки аларның имзаланган күчермәләрен теркәргә йә килешенгән вакытта аларны Инспекциягә тапшырырга мөмкин.

14. Төбәк операторы тикшерү акты һәм (яки) күрсәтмә белән килешмәсә, әлеге документларга карата төбәк операторы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

15. Тикшерү барышында җинаять җазасына китерә торган билгеләре булган хәл ачыкланган очракта, тикшерү актын Инспекция хокук саклау органнарына аларның компетенциясе нигезендә законнарда билгеләнгән вакытларда җибәрә.

_______________________________